ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.05.2021 с.Старое Дрожжаное №213

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске Ишле урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалын - «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Яңа Ишле башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе»н бетерү турында

Бюджет акчаларын тотуны оптимальләштерү максатларында, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законның 9, 22 статьяларына, Россия Федерациясе Граждан кодексының 61-64 статьяларына, «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясына, Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 статьясына, Яңа Ишле авыл җирлегендә яшәүчеләр җыелышының 2021 елның 26 маендагы 4 нче номерлы беркетмәсен исәпкә алып, Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске Ишле урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалын - «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Яңа Ишле башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе»н бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске Ишле урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалын - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Яңа Ишле башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе»н бетерү срогын - әлеге карарга имза салган көннән алып өч ай дип билгеләргә.

3. «Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУн ликвидация процедураларын тормышка ашыру өчен җаваплы итеп билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске ишле урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директорына:

4.1. Филиалны бетерү турында карар кабул ителгән көннән алып 15 көн эчендә мөлкәткә инвентаризация үткәрергә.

4.2. Файдалануга яраксыз һәм тулысынча таушалган милекне исәптән чыгаруга карата чаралар күрергә.

4.3. Мәгариф учреждениеләренең уставына, структурасына һәм штат расписаниесенә үзгәрешләр кертергә һәм вәкаләтле органнарда теркәргә.

5. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Яңа Ишле башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен бетерү буенча комиссия төзергә һәм аның составын кушымта нигезендә расларга.

6. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Яңа Ишле башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең ликвидация комиссиясе җитәкчесенә түбәндәгеләрне йөкләргә:

- Татарстан Республикасы буенча 8 нче Федераль салым хезмәтенең районара инспекциясенә муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен бетерү турында әлеге карар кабул ителгән көннән алып өч көн эчендә законнарда билгеләнгән тәртиптә хәбәр итәргә;

- Татарстан Республикасы буенча «Вестник государственной регистрации» журналының региональ вәкиллегендә муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен бетерү турында белдерүне (хәбәрнамәне) бастырып чыгаруны тәэмин итәргә;

- муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе мөлкәтенә инвентарьлаштыру үткәрергә һәм аны вәкаләтле органга тапшыруны тәэмин итәргә;

- хезмәт законнары нигезендә 2021 елның 1 августыннан муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе хезмәткәрләрен азат итү чараларын гамәлгә ашырырга;

- юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен законда билгеләнгән тәртиптә төшереп калдыру чараларын күрергә.

7. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе: Д.А. Сатдинов

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021елның 28.05 213 номерлы
карары белән расланды

Ликвидацияләү комиссиясе
составы

| | |
|---|---|
| Әхмәтов С. Л. | «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе методисты, комиссия рәисе, җаваплы ликвидатор |
| Хәбибуллина Г. Р. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе |
| Ханбиков Б. З. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе |
| Фәхертдинов И.Н. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске ишле урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБОУ директоры |

Башкарма комитетының
эшләре идарәчесе: Д. Р. Сабирҗанова